*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2021-2022 нче уку елы)
**4 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 60 минут**
**Максималь балл – 35**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Нечкә сузык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [у];
   ә) [ы];
   б) [о];
   в) [ө].

2. Яңгырау тартык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [к];
   ә) [г];
   б) [с];
   в) [п].

3. Иҗекләргә дөрес бүленмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *бү-ре-ләр*;
   ә) *эт-ләр*;
   б) *аю-лар*;
   в) *кош-лар*.

4. Синонимнардан торган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *нәни – кечкенә*;
   ә) *ак – кара*;
   б) *авыл – шәһәр*;
   в) *кара – кара*.

5. Ясалма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *өстәл*;
   ә) *чәчәк*;
   б) *мәктәп*;
   в) *күзлек*.

6. Урын-вакыт килешенең кушымчаларын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *-ның/-нең;*
   ә) *-га/-гә, -ка/-кә*;
   б) *-ны/-не*;
   в) *-да/-дә, -та/-тә*.

7. Саннардан торган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *урман, агач*;
ә) *мин, син*;
б) *ике, алты*;
в) *укыйбыз, язабыз*.

8. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Бүген дәрестә кем юк?*
а) хикәя;
ә) сорау;
б) боеру;
в) тойгылы.

## II. Теоретик бирем.

Күпнокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(5 балл)**

*[б] –* ..................... *тартык аваз. [ә] –* .............. *сузык аваз. Арка – арка –* .................... *. Мин, син, ул –* ...................... *алмашлыклары. Укыды –* ............. *заман хикәя фигыль.*

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(8 балл)**

*За нашим домом есть сад.*

*В саду растут яблони, груши, сливы и вишни.*

*Есть кусты малины.*

*На грядках растут лук, морковь и свекла.*

2. Бакчада тагын нәрсәләр үсә? Шул хакта 6 җөмлә языгыз. **(6 балл)**